Фәрдиева, Г. Урам бәйрәме / Г. Фәрдиева // Көмеш кыңгырау. – 2025. - № 36. – Б. 2.

# Урам бәйрәме

Ел саен Яр Чаллы шәһәрендә урам бәйрәме уздырыла. Күптән түгел «Квартал» территориаль иҗтимагый үзидарәсе ЗЯБ бистәсенең М. Бибишев исемендәге ял паркында зур бәйрәм оештырды. Анда 1нче китапханә-филиалы Бөек Җиңүнең 80 еллыгына багышланган «Сугыш уты чакрымнары» дигән китап күргәзмәсе белән катнашты. Шулай ук төрле темаларга уеннар үткәрде.

Әти-әни һәм балалар китап күргәзмәсен кызыксынып карадылар. Балалар рәхәтләнеп уйнадылар, викторина сорауларына җавап бирделәр.

**Гөлназ ФӘРДИЕВА,**
*Яр Чаллы шәһәре,*
*1нче китапханә-филиалы китапханәчесе.*

